

3/91
Март
ISSN 0868-4545
Сәләвәт күпере

Туган көнең мөбарәк булсын!

Яңгыр явып үткәннән соң, күк йөзендә галәмәт матур бер балкыш пәйда була. Аллыгөлле бу могҗизаи күренешне татар халкы «салават күпере» дип атаган. Башкортлар аны «йәйгор» ди, үзбәкләр «ук-җәй» дип исем кушканнар, төрекләр «күк кушагы» (күк билбавы) дигәннәр, урыслар «радуга» ди («шатлык дугасы»дыр, бәлки).

«Салават» сүзе гарәп теленә барып тоташа. «Салат» — «намаз уку, гыйбадәт кылу» мәгънәсендә, «салават» та шул ук тамырдан ясалган. Әйтик, намазның бер төрлесен «фарыз», ягъни мәҗбүри намаз дип атасалар, «Салаватен нафилә» фарыз булмаган намаз, ягъни бу намазны́ укысаң да ярый, укымасаң да ярый, гөнаһ булмый.

«Үткән эшкә салават», ди халык. Үткән эш кире кайтмый, үткән эшкә үкенмик; яхшымы ул, яманмы, без аны искә төшермик, без аңа салават әйтеп, дога кылыйк та онытыйк, мәгънәсендә.

Димәк ки, «салават күпере» дигәнебезне «яхшылык, иминлек күпере» дип аңлата алабыз. Бәхеткә илтә торган күпер икән ул Салават күпере.

«Салават күпере» исемле бу матур журнал Сталин хакимиятенең кара елларында да, торгынлык заманында да дөнья күрә алмады. Ниһаять, Тукай әйтмешли: «Т̂угыз корбан суеп алган теләк» тормышка ашты. Балаларыбыз өчен күп рәсемле, күп буяулы журнал чыга башлады.

Менә бүген «Салават күпере»нең туган көне. Аңа бер яшь тулды. Озын гомерле бул, «Салават күпере»!

Әкиятче БАТУЛЛА БАБАЙ.

И. Әхмәди рәсемнәре



ТАБЫШМАК

Шундый матур бер күпер —
Кеше йөрми, ай керми.
(Салават күпере.)

Газинур МОРАТ

ЯҢГЫРДАН СОҢ

Салават күпере чыкты.
Уйнарга чыкты Зилә.
Зилә белән шул күпердән
Чабып үтәсем килә.

ӘЙДӘГЕЗ, УЙНЫЙБЫЗ!



Бер бала икенче балага кул сыртын сузып тора. Икенчесе, аның кул сыртын сыйпый-сыйпый, тиз-тиз түбәндәгечә такмак әйтә:

Песи, песи, пес итәр,
Ана песи сөт эчәр.
Ана песи сөт эчкәндә,
Ата песи күз кысар.
Ал дигәндә алмасаң,
Лап итәр дә, шап итәр!

«Лап итәр» дигәндә, сыйпаганы тегенең кул сыртына шап иттереп суга. Әгәр теге бала кулын тартып алып өлгермәсә, отылган була.

© «Салават күпере», 1991 ел.






Лилия ХИКМӘТОВА рәсеме.
Зеленодольск районы.

Фирая ЗЫЯТДИН

Төшендем

Ашыккан ашка пешкән ди,—
Әбинең алтын сүзләрен
Әле генә төшендем:
Әни бүлеп биргән ашны
Кабаланып капкан идем,
Авызымны пешердем!



Ира ЛОГИНОВА рәсеме.
14 яшь. Казан шәһәре.

Заһирә ГОМӘР

Укып кара

Аю кабат табак юа.
Җире яктан карап,
Укып кара кабат:
АЮ ҖАБАТ ТАБАҚ ЮА.

Гөлназ ВӘЛИӘХМӘТОВА рәсеме.
8 яшь. Әлмәт шәһәре.





Лия ХӘКИМОВА рәсеме.
5 яшь. Сосновка шәһәре.


ЙОЛДЫЗ

Тал песие

Мин тал песи таптым,
Өемә алып кайттым.
Яныннан үтәм-сүтәм...
Мияулаганын көтәм.



Кичер мине... Гафу ит...



«Юри аякка баса да
Гафу үтенгән була...»

Тәртипсез малайлар шулай итә. Ә бит кайчакта кемнеңдер аягына ялгыш кына да басып куясың. Кызыпкызып уйнаганда берәрсенә бәреләсең, төртеп еккан чаклар да була. Була бит? Менә шундый күңелсезлек килеп чыкса, гафу үтенергә кирәк. Тик авыз эчендә ботка пешереп торма, ачы миләш яки балан капкандай йөзеңне дә чытма. Әдәпле генә итеп: «Гафу ит, ялгыш тиеп киттем»,— диген.

Әгәр инде кемне дә булса ачу белән рәнҗеткәнсең икән, хәзер эчтән генә сызланып йөрисең икән, үкенечкә калдырма. Бар булган кыюлыгыңны җый да: «Кичер мине, мин хаклы булмаганмын»,— диген.

Әйе, дөрес итеп гафу үтенә белү — үзе бер егетлек ул.

Әлифба

Каз
Капка
Курчак
Күбәләк
Көнбагыш










Бу рәсемгә карап, К хәрефенә башланган тагын ничә сүз табарсыз икән?

ТЕЛ КӨРМӘКЛӘНДЕРГЕЧ

Карга кара, кара карга,
Кар-рык, кар-рык карылдама;
Кардан калка кара карга,
Кара каурыйлары карга
Тарала да аунап кала.
Мин әйтә-лам, кем әйтә-ла?
Рамил, я син әйтеп кара.

Рәссам Алла АЙСИНА



Керпе

Борын-борын заманда җир йөзендә бөтенләй кыш булмаган, гел җәй генә патшалык иткән. Болыннар шау чәчәккә чумылып, агачлар мул җимештән сыгылып утыра икән. Кояш туры карагач, җәнлек-җанвар да көлмәкчән генә йөргән ди.

Бервакыт «Кыш килә!» дигән хәбәр таралган. Кыш үзе дә озак көттермәгән, суык җилләр

Хәйдәр

ТУНЫ

исә башлаган, кар төшкән. Җәнлек-җанвар бик аптыраган — нишләргә? Урман хуҗасы Аюхан күп уйлап тормаган, ерак таныш-белешләреннән барлык җәнлекләргә дә тун тектерергә җитәрлек тире кайтарткан.

Ул чакта Керпе тегүче булып эшләгән ди. Аның бик күп энәләре булган. Тотынган бу менә шул энәләре белән җәнлекләргә тун тегәргә. Кыш килеп җиткәнче һәммәсен дә тунлы иткән бит! Караса, үзенә тун тегеп киярлек тире дә калмаган. Шуннан соң Керпе күлмәгенә энәләр кадап чыккан да тунлы булган. Әмма аның туны салкын җилләрдән сакламаган шул...

Керпе, салкынга түзә алмыйча, җирне тишеп өн ясаган да шунда кереп яткан. Салкын кыш үтеп киткәнче өнендә йоклаган.

Бу хәлдән соң күпме заманнар узган инде. Әмма Керпе әле һаман да салкын кышларны өнендә үткәрә ди.





Рәссам Юрий ДЕНИСОВ



Иман рисаләсе

ӨЧЕНЧЕ САБАК

Сөаль:

— Аллаһы тәгаләне раслаучы сыйфатлар ничә һәм ул сыйфатлар кайсылар?

Җавап:

— Сигез. Ул сыйфатлар шулар: хәят, гыйлем, сәмигъ, басыйр, ирадәт, кодрәт, кәлям, тәкәүвен.



СӨАЛЬ:

— Боларның мәгънәләре ничек?

ҖАВАП:

— ХӘЯТ МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгалә теректер, тереклеге безнең кебек түгелдер.

ГЫЙЛЕМ МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгалә белүчедер, белемлеге безнең кебек түгел

СӘМИГЪ МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгалә ишетүчедер, безнең кебек колак белән түгелдер.

БАСЫЙР МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгалә күреп торучыдыр, күрү рәвеше безнең кебек күз белән түгелдер.

ИРАДӘТ МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгалә теләүчедер, әмма теләге безнеке кебек түгелдер.

КОДРӘТ МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгаләнең көче җитештер, көченең җитмәклеге безнең кебек кораллар белән түгел, кәмал кодрәте беләндер.

КӘЛЯМ МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгалә сөйләүчедер, сүзләре безнең кебек тел һәм авыз белән түгел, бәлки үзенең камил кодрәте беләндер.

ТӘКӘҮВЕН МӘГЪНӘСЕ — Аллаһы тәгалә юктан бар кылучыдыр, бар кылганы камил кодрәте ярдәмендәдер.

Сәхифәне Фәрит ЯХИН алып бара.

Рәссам Надир АЛЬМЕЕВ





КӨН нәрсә ул? ТӨН нәрсә?



Бервакыт кич белән, әти һәм әни эштән кайткач, гаиләбез түгәрәкләнгәч, энем Рөстәм зур ачыш ясагандай:

— Хәзер ник караңгы икәнне мин беләм! — дип куйды.

Билгеле, мин дә белә идем, әмма энемне тыңлап карыйсым килде.

— Кояш барыбыздан да алда тора, көне буе эшли,— дип аңлата башлады ул,— безгә якты һәм җылы бирә, шуңа күрә кич җиткәндә аның көче бетә. Кич җиткәч, кояш ял итәргә китә. Белдеңме?

— Юк, алай түгел,— дидем мин.

— Алайса, ник көн һәм төн була?

— Тубыңны алып кил әле.

Рөстәм карават астыннан туп тәгәрәтеп чыгарды.



Рәссам Илдар Әхмәдиев

— Түшәмдәге утны кояш дип уйлыйк. Күрәсеңме, ул селкенми, бер урында эленеп тора. Кояш та шулай.

— Кояш чыга да, бата да. Күк йөзендә йөри бит ул,— дип аптырады Рөстәм.

— Безгә шулай тоела гына. Кояш йөрми. Тупны менә шулай итеп тот әле. Ул Җир шары булсын. Хәзер мин туп өстенә фломастер белән тамга төшерәм. Анысы безнең Казан шәһәре булыр. Кара, ноктага ут яктысы төшми. Күрәсеңме?

— Күрәм!

— Димәк, бездә хәзер төн. Тупның теге ягы якты. Димәк, анда көн. Хәзер тупны акрын гына әйләндерә башла.

— Нигә?

— Җир шары шулай әйләнә. Әнә, безнең ноктага якты төшә башлады, таң атып килә. Менә хәзер ут туп-туры карый, көн уртасы җитте, димәк.

Рөстәм тупны тагын бераз әйләндергән иде, «Казан» кабат караңгыда калды.

— Җир шары бер тапкыр әйләнеп чыкканда бер тәүлек узган була: төн, иртә, көн, кич...

— Менә кызык, кояш бер дә ял итми икән,— дип гаҗәпләнде Рөстәм.

НӘҮРҮЗ БӘЙРӘМЕ

БЫЛБЫЛДАН АВАЗ КИЛДЕ...

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Былбылдан аваз килде —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Абзый эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң, ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын —
Нәүрүз мөбарәк булсын!



Элгәре заманнарда безнең бабаларыбыз, безнең бабаларыбызның бабалары Яңа ел бәйрәмен 22 мартта уздырганнар. Аны НӘҮРҮЗ БӘЙРӘМЕ дип атаганнар.

Ошбу көнне малайлар вә кызлар, һәр өйгә кереп, хуҗаларга такмак-такмаза әйткәннәр, аларны бәйрәм белән котлаганнар.

Рәшит ЯГЪФӘР

Рәссам Рафаэль СИРАҖЕТДИНОВ



Ватаныны саклыйк!

Булат белән Сөмбел Бөек Болгар шәһәрен бик озак карап йөрделәр.

— Алҗыдым мин,— диде Сөмбел.— Өйгә кайтасым килә, әтине-әнине сагындым.

Булат борынын җыерып куйды. Кызлар шундый инде ул! Алар белән сәяхәткә йөрү кыен. «Сагынды-ым!» — дип елый башламасын тагын.

— Әйдә алайса су коенабыз,— диде ул сеңлесен юатырга теләп.

Елгада кеше күп иде — олысы-кечесе Идел дулкыннары кочагында кинәнәләр.

Шулвакыт кырмыска оясына таяк тыккан кебек булды. Һәркем каядыр чабыша, бала-чага елый, кояшны да болыт каплады сыман.

Булатның эченә шом йөгерде. Ул бер малайга эндәште. Нәрсә булды, янәсе.

— Урыс явы! Урыс явы килә! — диде тегесе туктап тормыйча гына.

Шәһәр капкалары ачылды, аннан атка атланган болгар яугирләре чыга башлады. Дәү калканнары бихисап кояшлар кебек ялтырый! Алар артыннан җәяүле сугышчылар кузгалды. Билләрендәге кылычлар бихисап яшеннәр кебек уйный!

Булат, сеңлесен дә онытып, шуларга тартылды. Ләкин шул чагында янәшәдә генә Вакыт машинасы пәйда булды. Кызыл утларын җемелдәтеп, малайга эндәште ул:

— Син монда кунак кына, Булат,— диде.— Ашыкма. Туган илне үзең яшәгән заманда да дошманнан сакларга туры килер әле!

— Ә хәзер кем җиңәр соң? — диде Булат кызыксынуын яшерә алмыйча.

— Бу юлы сугыш булмый,— диде Вакыт машинасы.— Баһадир Добрыня урыс гаскәрен кире борды. «Болгарлар барысы да итек кигән,— диде ул үз кенәзенә,— без алардан салым ала алмабыз».

Урыс гаскәре сугышыр өчен чабаталы халыкларны эзләп китте.

КЕНӘЗ — борынгы заманда урыс патшаларын шулай атаганнар.
САЛЫМ — җиңүчегә түләнәсе акча, тауар.



Рәссам Рушан ШӘМСЕТДИН

Нур ӘХМӘДИ

ЧӘКЧӘК

Әнкәй пешерде чәкчәк,
Капкалыйм аны чәк-чәк.
Мин ашагачтын чәк-чәк,
Чәкчәк тә кими чәк-чәк.

Баллы чәкчәк,
Тәмле чәкчәк
Кимесә шулай чәк-чәк,
Әбигә дә җитәчәк,
Бабайга да җитәчәк.
Тик кызганыч шунысы —
Барыбер бер бетәчәк.

Рәфис ӘХМӘТ

СЫКЫ

Тимерчыбыклар да хәтта
Калтырый, чиный туңып.
Юкка мени карт Кыш бабай
Төн буе тегә толып?

Маңгаеннан пар бөркелә,
Тегә-тегә талчыккан,
Толыбының һәр җиренә
Мең энә кадап чыккан!

Бабай теккән ак толыпны
Әллә алып кигәнме?
Ак керпегә охшап калган
Бакча арты кибәне!

Ә һавада әле һаман
Очып йөри энәләр,
Гүя шәрә агачларга
Сихри күлмәк чигәләр...

Ай-һай тырышкан Кыш бабай,—
Бөтенләй качкан йокы...
Төн эчендә һәммә җирне
Сарып алган ак сыкы!

Рөстәм МИНГАЛИМ шигырьләре

ИҢ ЗУР КЕШЕ

**Күпне белгән кеше —
ул зур кеше була...
Күптән — күпне белгән —
бик зур кеше була.
Бик зур кешегә дә
тиң зур кеше була.
Әти-әнидән дә
зуррак кеше
булмый:
шуны белгән кеше —
иң зур кеше була!**

КӨРӘК

**Карлар көри юлдан,
көри-көри көрәк:
сыерга юл — кирәк,
сарыкка юл — кирәк!
Песигә юл — кирәк,
кешегә юл — кирәк!**

**Юлдан карлар көрәп,
арып беткән көрәк.**

**Йоклап киткән көрәк,
башын карга терәп.**

**Инде ул төш күрә,
бер төш күрә көрәк:
йөри
көрәк
карны
кабат юлга көрәп.
Сарык баткан юлда,
сырты гына күренә.
Тездән карга баткан
сыер тора мөгрәп.
Начар төш бу, көрәк!
Уян тизрәк!**

Рәссам Зөфәр ХӘКИМ

ӘНИЛӘР,
ӘТИЛӘР,
ӘБИЛӘР,
БАБАЙЛАР,
АПАЛАР,
АБЫЙЛАР —

БЕЗНЕҢ ӨЛКӘН ДУСЛАРЫБЫЗ!

«Салават күпере» журналы чыга башлаганга бер ел булды. Инде менә журнал турында сезнең фикерләрне ишетәсебез килә. Сорауларга мөмкин кадәр тулырак итеп җавап бирсәгез иде. Адресыбыз: 420012 Казан, Комлев урамы, 14 нче йорт, «Салават күпере».

1. Журналны ничә яшьлек бала өчен сатып аласыз?
2. Ул аны үзе укыймы, өлкәннәр укып бирәме?
3. Журналның кызыгы ничә көннән бетә? Нинди рәк язма һәм рәсемнәр кызыксыну уята, кайсылары кызыксыз яки катлаулы?
4. Рәссамнарыбыздан кемнәрне аеруча ошаттыгыз? Журналның бизәлешенә нинди билге куяр идегез?
5. «Салават күпере»н чыгаручыларга нинди тәкъдимнәрегез бар?

Игътибарыгыз өчен алдан ук рәхмәтләребезне белдерәбез. Кызыклы һәм эшлекле хатларның авторларына журналның бүләген җибәрергә ниятләп торабыз.

Редакция.

ӘНИЛӘРГӘ
ҺӘМ
НӘНИЛӘРГӘ

Мөдәррис Әгъләмов

БИШЕК ЖЫРЫ



Кояш инде тәгәрәп
Төште таулар артына;
Әлли-бәлли-бәү, диеп
Әнә Чулпан яктыра —
Әлли-бәлли-бәү, диеп.

Дәү әниең эләргә
Биләүләрең чайкады.
Әлли-бәлли-бәү, диеп
Тәрәзәдән ай карый —
Әлли-бәлли-бәү, диеп...

Дәү әтиең шым гына
Йөри аяк очында...
Әлли-бәлли бәү, диеп
Көйлимен баш очында —
Әлли-бәлли бәү, диеп...


Урамдагы йортларда
Тәрәзәдә утлар да
Әлли-бәлли-бәү, диеп
Чакыралар йокларга,
Әлли-бәлли-бәү, диеп.

Әлли-бәлли, йокла тыныч,
Әлли-бәлли, уян көнем;
Әт-тәң-не дә сөендереп,
Ән-нәң-не дә сөендереп,
Уян көлеп,
Әлли-бәлли-бәү...бәү...бәү...

Рәссам Елена ХИТРОВА







Син мавыгып рәсем ясыйсың. Шулчак әбиең (бабаң) сиңа ягымлы елмаеп эндәшә:

— Бәбкәем (улым, кызым), күзлегемне генә табып бирсәнә. Кая куйганымны хәтерләмим генә бит.

Син тыңлама:

— Әйем лә,— диген. Рәсем ясавың белән мәшгуль бул.

Әбиең (бабаң) — синең яраткан әбиең (бабаң) — уфылдый-уфылдый күзлеген эзләр. Эзләсен. Бервакыт үзеңнең әби (бабай) буласың хакында да уйлама, үзеңнең шулай әйбер-мазар эзләп азаплануыңны да күз алдына китерергә тырышма...

Синең инде рәсем ясыйсың килми, ләкин шундый рәхәт, күңелле!

Әллә... киресенчәме?

Салават күпере

3(13)—1991

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ СОВЕТ-ФИН УРТАК ПРЕДПРИЯТИЕСЕ «ПОИНТ» ЖУРНАЛЫ

1990 ЕЛНЫҢ МАРТ АЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Айдар ҮТӘГӘН

Исәп-хисап бүлеге
Розалия ЗАРУБИНА

Тышлыкның беренче битендә — Елена ХИТРОВА, дүртенче битендә — Айдар ҮТӘГӘН рәсемнәре

КПССның Татарстан Республика комитеты нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Правления Союза писателей ТССР и Советско-Финского совместного предприятия «ПОИНТ» (на татарском языке). Основан в 1990 году.

Адрес редакции: 420012, г. Казань, ул. Комлева, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 18.02.91 ел. Басарга кул куелды 04.04.91 ел. Кәгазь форматы $84 \times 108^1/_{16}$. Басма табак 1,0 (2,1). Нәшер-хисап табагы 3,09. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 25 мең данә. Заказ И-73. Бәясе 1 сум.

Бәясе 1 сум


1/90
Салават күпере


4/90
Салават күпере


5/90
Салават күпере


2/90
Салават күпере


3/90
Салават күпере


6/90
Салават күпере


7/90
Салават күпере


8/90
Салават күпере


9/90
Салават күпере


10/90
Салават күпере

